# Шигъри сандык

№ 3 Февраль 2023 ел



Кайвакытта син сорыйсың,
дустым:" шигырь язу
Ничек була дип? "
Көтмәгәндә пәйда була ул:
Төрле кыяфәттә бирә кул:
Я матур кыз, я батыр ул,
Ярый әле, алай булса ул,
Иң күбесе - бәйләнчек уй
Аның сәбәбе...
Шуннан, күңелеңдә йөргән
шигырь оеткысы хисләр
күәсеннән ярсып чыга.
Өметләнмә аннан котылам дип,
Теләсә кайдан таба ул сине:
Кунакта да, аулакта да,
Кирәк булса, йокыңнан да уята,
Киреләнеп маташма да:
Җилтерәтә, тинтерәтә,
Барыбер җиңә, үзенекен итә:
Кулларыңнан эшең ала,
Бөтен ниятләрне үзгәртә,
Вакыт югын да ул аңламый,
Бернинди дә ай-ваеңа карамый
Алып килә өстәл янына.
Күз алдында китер әле, дустым:
Таңмы ул, дөм караңгы төн уртасы
Яки көпә-көндез кырыкка
ярылганда:
Син - җитди генә бер кеше
Утырасың шигырь язып,
Әллә ни майтаргандай,
Бер эшең булмагандай.
Мин беләм: бу "өянәк"
Тик кенә үтеп китми,
Теге оеткыдан бер шәп
Шигырь язылмый калмый.
Ничә тапкыр кыен хәлгә куйды
Шушы халәтем мине.
Хикмәт дими ни диярсең,
Шигырь ничек язылганын
Аны тасвирлап булмый:
Күңел үзе тула,
Илһам үзе килә,
Сүзләр сүзгә ялганып
Шигырь үзе туа.

*РАЯН ШАКИРОВ*